ҮЗӘККӘ ҮТТЕ
Бер сүндергәч, җылылыкны кире кайтару – катлаулы эш.

> 2

АВЫЛ МАЛАЕ
Быел Туфан ага Миңнуллинның бакыйлыкка күчүенә ун ел тулды

> 3

ИЛДУС ЛОТФУЛЛИН:
«Бала тәрбияләү – зур эш. Ни дисәң дә, җенескә карамый ул»

> 4

ЯЗУЧЫ ФИКЕРЕ
«Барысы да алдый, әлбәттә. Тик һәркайсы үзенчә»

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 72 (28845) | Чәршәмбе | 25 май | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Сәрия МИФТАХОВА

ОЛЫ ЮЛ БАШЫ

Республика мәктәпләрендә соңгы кыңгырау чыңлый. Һәр елдагыча, моңсу да, шул ук вакытта киләчәккә канат куя торган да бу чыңлау. Быел 11 нче сыйныфны – 15648, 9 нчы сыйныфны 37757 укучы тәмамлый. Укытучылар укучыларга тизрәк хәер-фатыйхасын биреп калырга ашыга. Ә алар олы тормышта беренче адымнар ясарга әзерме соң?

– Инде артта калган дәрес, тәнәфес, өй эшләрен берничә елдан сез сагынып искә алырсыз. Әмма бүген күңелдә – бары тик дулкынландыргыч шатлык кына. Сезнең тизрәк мөстәкыйль тормышка, якты хыялларга илтә торган юлга аяк басасы килә. Ә ул юл нинди булыр – анысы һәркемнең үзеннән тора, – диде Татарстан мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин башкалабыздагы 139 нчы гимназиядә узган тантанада.

Әлеге уку йортында 11 нче сыйныфны 48 укучы тәмамласа, шуларның сигезе медальгә өметләнә.

– Безгә төпле белем биргән укытучыларыбызны, мәктәбебезне сагынырбыз. Аерыласы килми, әмма алда безне бөтенләй башка тормыш көтә. Күп нәрсәне үзебезгә хәл итәргә өйрәнергә туры киләчәк. Мин табиб булырга телим. Мәскәү, Санкт-Петербург вузлары кызыксындырса да, үзебездә калырга җыенам. Әлбәттә, БДИ куркыта. Әмма унбер ел буе өйрәнгәнебезне имтиханда акларбыз дип ышанам, – ди 11 нче сыйныф укучысы Алиса Ессенина.

Кызлар – ак алъяпкычтан, гольфыдан, егетләр – костюмнан…. Бер караганда, үткәннән ерак китмәгәнбез дә кебек. Совет чорындагы мәктәп формасының әле дә саклануына карата министр да уңай фикерен белдерде. «Бу бит безнең балаларны тәрбиягә өнди. Кызлардан аклык, пакьлек бөркелә. Мәктәп формасы булу безне сөендерә», – диде ул.

Рәхмәт сүзләре, чәчәк бәйләмнәре, күз яшьләре… Хушлашу тантанасында халәт шундый. «Мондый очрашу башка булмаячак». Укучылар да, укытучылар да әнә шул сүзне кабатлый. Әнә Илсур Һадиуллин да 40 ел элек яңгыраган соңгы кыңгырау тавышын әле дә онытмый икән, һаман да колакта яңгырый, ди.

– Гомерлеккә истә кала ул. «Мин инде зур булдым!» дигән горурлык сизәсең. Алда бурычлар тора, син аны үтәргә, имтихан бирергә тиеш. Мин Балык Бистәсе районының Шеморбаш мәктәбен тәмамладым. Ул – кечкенә генә мәктәп. Безгә яшь вакытта 40 елдан соң мәктәпне бетерүчеләр бик олы күренә иде. Әлбәттә, без дә яшьләргә шулай күренәбездер. Әмма йөрәк картаймый, алга таба яшәргә омтыласың. Мәктәп белән горурланырга кирәк. Ул – яктылык һәм белем учагы. Укытучылар безгә белем һәм тәрбия биргәннәр. Без шуның белән яшибез, – диде министр.

Быелгы уку елы нинди вакыйгалар белән истә калачак? Илсур Һадиуллин әйтүенчә, укучыларның белемгә булган омтылышы кимеми, ул үсә бара. Олимпиада җиңүчеләре буенча Татарстан өченче урында санала. «Бу – республика өчен зур көрәш, җиңү. Президентыбыз предприятие, кече һәм урта бизнеска мөрәҗәгать итеп, бәйгеләрдә җиңгән балаларга бирелә торган акчаның бәясен күтәрде. Элек 50 мең булса, быел аның күләме – 200 мең сум. Призерларга хәзер акча дүрт тапкыр күбрәк бирелә. Бу – 100 мең дигән сүз. Методистларның хезмәт хакы ике тапкыр артты. Алар моңа кадәр укытучыдан да азрак ала иде, бу бер дә мактана торган әйбер түгел. Президент катлаулы икътисади чорда шушы мәсьәләне дә хәл итте, – диде министр. – Яңа мәктәпләр ачылды, укытучыларның белемен күтәрүдә яңа үзгәрешләр кертелде. Татар теленнән олимпиадалар үтте. Цифрлаштыру елында 1 нче сыйныфка кабул итү тәртибе үзгәртелде. Хәзер гаризаларны портал аша тапшырып була. Мәгариф ул – безнең тормыш. Аннан башка беребез дә яшәешне күз алдына китерә алмый».

Ахыры 2 нче биттә >

Белешмә

Быел республикада **11** нче сыйныфны **15648** укучы тәмамлый, шуларның **5797**се – Казанда (узган елда бу сан – **15886**, шул исәптән башкалада – **5833**); **9** нчы сыйныфта **37757** укучы белем алса, шуларның **11798**е – Казанда (узган ел барлыгы – **35876**, Казанда – **11279** укучы).

Ял өчен акча кайта

Балалар лагерьларына юллама алучыларга барлыгы 6 миллиард сум акча кире кайтарылган инде. Россия вице-премьеры Дмитрий Чернышенко әйтүенчә, кешбэк программасы башланганнан бирле ата-аналар җәмгысы 13,7 миллиард сумга 420 меңнән артыграк юллама сатып алган. Кешбэк аларның «Мир» түләү картасына кайтарылган. Чернышенко искә төшереп үткәнчә, балалар лагерена юллама бәясенең яртысын каплау Хөкүмәтнең халыкка ярдәм итү буенча тиз генә күрелгән чараларының берсенә әйләнгән.

Балалар кешбэгы буенча юлламалар сату 31 мартта башланып, җәй ахырына кадәр дәвам итәчәк. Лагерьлар аларны инде 1 майдан кабул итә башлады. Программаны гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан 7,5 миллиард сум бирелгән. Узган елда шуның ярдәмендә 400 меңнән артыграк бала ял иткән.

Җәй соңара

Быел май ае суык килде. КФУ профессоры, география фәннәре докторы Юрий Переведенцев әйтүенчә, җәй дә ашыкмый әле. Аның сүзләренә караганда, 26–30 май көннәрендә тәүлеклек уртача температура норма буенча 15 градус тәшкил итәргә тиеш. Әмма башлангыч фаразларга караганда, 26 майда бу күрсәткеч 6–7 градуска кимрәк булачак. Яңгырлы, суык май җәй килүне тоткарлый.

Профессор аңлатып үткәнчә, хәзер безгә Арктика һавасы йогынты ясый. Язгы «котып суыгы» атна ахырында гына чигенә башлаячак. Россия Гидрометеоүзәгенең башлангыч фаразы буенча, июнь аенда температура норма чикләрендә тирбәләчәк. Ә менә июльдә янә нормадан түбәнрәк булачак.

«Тукай картасы» әзерләнә

Татарстанда «Тукай картасы» проектын гамәлгә ашыру өчен ведомствоара эш төркеме булдырылган. «Реальное время» интернет басмасы хәбәр итүенчә, карта республикада яшәүче 10–13 яшьлек үсмерләргә биреләчәк. Шул ук вакытта «Пушкин картасы»ның 14–22 яшьлекләргә тәгаенләнүен искә төшерик.

Хәзерге вакытта яңа проектны тормышка ашыру юллары карала. Республикада «Пушкин картасы»на охшаш «Тукай картасы»н булдыруны мәдәният министры Ирада Әюпова тәкъдим иткән. Аны театр-музейларга йөрү өчен билгеләү планлаштырыла.

Тәкъдимне Дәүләт Думасының Мәдәният комитеты рәисе Елена Ямпольская Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгатьне үстерү буенча республика советы утырышында хуплаган.

«Рубин» ФНЛда чыгыш ясаячак

Футбол буенча Россия премьер-лигасында киләсе сезонда да 16 команда чыгыш ясаячак. Россия футбол берлегенең башкарма комитеты шундый карар чыгарды. Шулай итеп, Казанның «Рубин» командасы алга таба ФНЛда чыгыш ясарга мәҗбүр булачак.

Билгеле булганча, узган шимбәдә Казан командасы үз кырында «Уфа»га оттырып, сезонны 15 нче урында тәмамлады. Әмма «Рубин»да, премьер-лигада чыгыш ясаучы командалар саны арттырылган очракта, иң көчлеләр сафында калырга өметләнде. Ахыр чиктә Россия футбол берлегендә кабул ителгән карар «Рубин» файдасына булмады. Казан командасы 2003 елдан бирле премьер-лигада чыгыш ясады. Инде хәбәр иткәнебезчә, команда белән алга таба да Леонид Слуцкий идарә итәчәк.

ФНЛда Татарстаннан тагын бер команда – Түбән Камадан «Нефтехимик» та уйный. «КАМАЗ» исә әлеге турнирдан төшеп калды.

rubin-kazan.ru

Сәламәтлек

Аермасын саулыктан!

ТАТАРСТАНДА СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ ОБЪЕКТЛАРЫ ӨЧЕН 7,5 МЛРД СУМ АКЧА ТОТЫЛАЧАК

Һәрбер тармактагы кебек үк, сәламәтлек саклау юнәлешендә дә мәңгелек сораулар бар. Ул да булса – белгечләр мәсьәләсе һәм төзекләндерү эше. Икесен дә төрле программалар ярдәмендә чишәргә тырышалар. Соңгы елларда нәтиҗәсе күзгә күренә кебек.

Хөкүмәт йортында Татарстанда сәламәтлек саклауның беренчел звеносын заманчалаштыру төбәк программасын тормышка ашыру турында сөйләделәр. Кайда яңа бина сафка баса, кайда нинди белгеч җитми, табибларны ничек кызыксындыралар – брифингта катнашучылар шул сорауларга җавап бирде.

– Республикада икенче ел рәттән сәламәтлек саклауның беренчел звеносын яңарту программасы тормышка ашырыла. Ул «Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты кысасындагы бер юнәлеш булып тора. Төбәк программасына Сәламәтлек саклау тармагы карамагында булган беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче барлык медицина оешмалары (аларның саны – 83. – **Авт.**) да кертелде, – диде Татарстанның сәламәтлек саклау министры Марат Садыйков.

Узган ел бу юнәлеш буенча шактый эш башкарылган. Әйтик, 2021 елда 12 яңа медицина корылмасы сафка баскан, 27се төзекләндерелгән. Татарстанның 43 районында яшәүче кешеләр өчен хәзер медицина ярдәмен алу күпкә уңайлырак һәм җиңелрәк дигән сүз инде бу. Программаны тормышка ашыру өчен 2,5 млрд сум акча бүлеп бирелгән. Шуның өчтән бере яңа корылмалар төзүгә, тагын шул чама акча машина сатып алуга тотылган.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Авыл табибы» программасы кысасында 2012 елдан башлап авылларга 868 табиб һәм урта медицина хезмәткәре җәлеп ителгән. 2022 елда 104 белгеч кайтырга тиеш. Табиблар белән тәэмин ителеш 10 мең кешегә – 35,8 хезмәткәр (2021 елда).

Узган ел медицина җиһазларын яңарту юнәлешендә дә эш алып барылган. Моның өчен 223,4 млн сум акча бирелгән.

2022 елда да программаның бурыч-максатлары үзгәрешсез кала. Яңарту көткән биналар да, җиһазлар да аз түгел. Быел тармакның беренчел звеносына матди ярдәм күләме 2,4 млрд сум булачак икән.

Марат Садыйков әйтүенчә, 34 яңа корылма сафка басачак, 15ен төзекләндерү ниятләнә. Тагын 17 берәмлек транспорт сатып алыначак. Шушы акча медицина җиһазы сатып алуга да тотылачак.

Ахыры 2 нче биттә >

Сүзгә-сүз

Николай ПАТРУШЕВ, Россиянең Иминлек советы секретаре:

Үз һөнәренә тугры калган, гомерләрен тәрбиягә багышлаган педагогларның абруен күтәрергә кирәк. Чөнки бүген тарихи традицияләрне торгызу, шулай ук илнең традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрен саклау – төп бурычларның берсе. Аны хәл итү өчен, тәрбия һәм белем бирүне билгеле бер системага салырга кирәк.

(«Аргументы и факты» басмасында чыккан әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – ҺӨНӘРЛӘР

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы җиде елдан соң кайсы белгечлекләргә ихтыяҗ булачагы турында хәбәр итте.

ФАРАЗ

192 мең кеше *(гомуми ихтыяҗ)*

30 мең кеше *(2023 елга ихтыяҗ)*

НИНДИ БЕЛГЕЧЛӘР КИРӘК?

Аппаратчы, машинист-кранчы, монтажчы, пешекче, кондитер, эретеп ябыштыручы, токарь, фрезеровщик, слесарь, шәфкать туташы, музыкаль, мәктәпкәчә белем бирү юнәлешендәге белгечләр, товар сыйфатына экспертиза ясау буенча белгеч



Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

КЫТАЙНЫ ЕГЫП БУЛЫРМЫ?

Соңгы көннәрдә Америка – Кытай кучәре тирәсендә конфликт көчәя. Әлбәттә, бу глобаль кризисның үсеше белән бәйле. Үткән атнаның чәршәмбесендә Американың акцияләр базары 2020 елдан соңгы иң көчле түнтәрелеш кичерде. Акрын гына түбәнгә тәгәрәү – аларның финансылары өчен хәзер гадәти күренеш. Кисәк мәтәлчек атулар да еш була. Үткән чәршәмбе шуның бер мисалы иде. Бу юлы әйләнеп капланунның сәбәбе Target һәм Walmart ритейлерларының хисабы булды. Ике компания дә табышның көтелгәннән кимрәк икәнен күрсәттеләр һәм бәяләр түбәнгә очты. Беренчесе 27 процент кыйммәтен югалтты, икенчесе сишәмбе көнне үк 11 процентка арзанайган иде, чәршәмбедә тагын 7 процентка очсызланды. Башка ритейлерлар да бәя югалтты. Amazon, мәсәлән, 6,6 проценттык түнтәрелеш кичерде. Мәтәлчек ритейлерлар белән генә туктап калмады, билгеле. Базарның барлык тармакларына да кучте. Nasdaq биржасы үткән елның ноябрендә үзенең иң югары кыйммәтенә ирешкән иде. Хәзер ул бәядән 29,6 процентка очсызланды, S&P 500 18,6 процентка арзанрак бәяләнә. Биржа сәүдәсенең югары ноктасында боларның акцияләрен сатып алучыларның хәлен күз алдына китерегез.

Кытайда да хәлләр яхшы түгел. Илнең үсеш темплары АКШныкыннан калыша башлады. Бу – алар өчен көтелмәгән хәл, сызландыра торган күренеш. Ике гигант җитештерүче, ике гигант базар үз югалтуларын бер-берсе хисабына капларга һәм кризисның гаеплесен атарга тиеш булып чыгалар. Вашингтон Кытай икътисадын көчсезләндерү өчен чараларны көчәйтте. Apple үз продукциясен Кытайда җитештерүне туктатып, Һиндстанга һәм Вьетнамга күчерергә җыена. Янәсе, карантин чаралары артык кырыс һәм «башка сәбәпләр» бар. Моннан тыш Токиода бара торган Quad (куркынычсызлык буенча АКШ, Австралия, Япония, Һиндстан арасындагы дүртьяклы диалог) саммитында Кытайны Һинд – Тын океан төбәгендә законсыз балык тотуда гаепләүгә ниятләрләр. Торакны онлайн броньлаштыру сервисы Airbnb та үзенең бирәдәге бизнесын ябып игълан итте.

Икътисади басым белән генә чикләнмиләр. Андый басым базарларны тотрыкландырмый. Шул тотрыксызлыкны (кискен түбәнгә сикерүләрне), Тайвань тирәсендә конфликтны көчәйтеп, икътисади түнтәрелеш сылтау итмәкчеләр. Байден Токиода Кытайның Тайваньга агрессиясе башланса, АКШның турыдан-туры хәрби тыкшынуы белән янады. Бу державалар арасында зур сугыш башлануын аңлатачак.

Байден үзенең Азия буенча сәяхәте кысасында Сеулга да килде. Көньяк Корея Вашингтонның Кытайга икътисади басымын яклавын белдерде. Кытай Үзәк банкының әлекке әгъзасы Юй Юндин: «Россия Үзәк банкының активларына салынган арест Кытайның чит илдәге активларына зур куркыныч янавын белдерә», – дип чыгыш ясады. Халыкара валюта фонды: «Дөнья икътисады Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң иң начар хәлдә», – дип игълан итте. Нинди хәвефле заманда яшәвебезне шуннан үзегез аңлагыз.

Россиядә

СТАТИСТИКА НАЧАР ТҮГЕЛ, ӘММА...

Көнбатышның куәтле санкцияләре астында яшәвебезнең дүртенче аена аяк басарга җыенабыз. Вашингтон һәм Брюссель безгә карата глобаль изоляция үк оештыра алмадылар, вәләкин икътисади хәлебез сизелерлек начарайды. Углеводородларның, бигрәк тә газның югары бәясе Россиягә үз җилкәсен куя әле. ОПЕК+ илләре Мәскәүне читкә какмадылар, Вашингтонның ташлап, Кытай һәм Россия белән аркадашлык итүгә күчтеләр. Согуд Корольлегендә соңгы көннәрдә генә ОПЕК+ килешүе, санкция басымына карамастан, Россия катнашында тәэләнәчәген әйттеләр. Бу – Россия өчен тышкы мәйданда зур уңыш, билгеле. Индонезия 28 майдан башлап пальма маен экспортлауга чикләүне бетерәчәген дә игълан итте. Димәк, көнфит ашарбыз, дип уйлыйк. Язның килеше зур иген уңышына да өметләрне көчәйтә. Әмма без Кытай ук түгел. Пекинда зур кризиска һәм ачлыкка төптән һәм ныклап әзерләнгәннәр. Бөтендөнья ашлыгының 69 проценты (дөгенең – 60, бодайның – 51 проценты) – шулар амбарында.

Безнең белән мөнәсәбәтләрне саклаган «дус ил»ләрнең күп булу да хәлне җиңеләйтә. Әмма аларга да ахыргача ышанып булмый, чөнки берәүнең дә АКШ һәм Европа белән мөнәсәбәтләрне катлауландырасы килми. Казахстанда әле генә Россия банкларының филиалларындагы 21,5 миллион доллар акчаны «туңдырдылар». Моны «санкция таләпләре» белән аңлаталар.

Илнең эчке базарында да икътисад белән бәйле проблемалар арта. Росстат начар статистика күрсәтми үзе күрсәтсен. Чит ил брендларының Россияне ташлап китүләренә карамастан, эшсезлек күрсәткече түбән. Әмма меңләгән хезмәт күрсәтү предприятиеләре эштән туктадылар, күп кенә эре сәнәгать тармаклары вакытлыча дип аталган ялда, кече бизнес хезмәтенә һәм үзмәшгульләрнең ярдәменә ихтыяҗ кими. Мәҗбүри ялга китүләр, җитештерүнең кимүе хезмәт хакларын кисә, халыкның тулаү сәләте югала. «Ромир» холдингы белдерүенчә, россияләрнең 47 проценты озак сроклы куллану товарларын һәм кыйммәтле әйберләр сатып алуны туктаткан. Гражданнарның 43 проценты бары тик ашау-эчү чыгымнары белән генә чикләнәләр, халыкның 30 проценты өстәмә керемнәр эзләү белән мәшгуль.

Эш бирүчеләрнең хезмәт хакларын киметүе гадәти күренешкә әйләнә язды. Хәтта ай-ти компанияләрдә дә хезмәткә түләүне ел ахырына кадәр 25 процентка кадәр киметүчеләр бар. Вакытлыча туктап калган эре предприятиеләр хезмәт хакының өчтән ике өлешен генә түли. Доллар һәм евроның курсы түбәнәю базарда бәяләр түбәнәюендә чагылмый диярлек, алар һаман да югары. Әмма бу вазгыятьне файдаланырга була. Соңгы атнада Төркиянең резервлары 4,8 миллиард доллар югалттылар, алар өчен бу – «шоклы кимү». Бу төрек лирасының чираттагы девальвациясен вәгъдә итә. Бездә – ныгу, аларда – девальвация. Төрек күчемсез милке россиялеләр өчен ике тапкыр һәм аннан да күбрәк очсызлана дигән сүз. Хәзер Россиянең Үзәк банкы бер айга илле мең долларга кадәр акчаны чит илләргә күчерергә рөхсәт итә. Димәк, акчасы булганнар өчен мөмкинлекләр арта. Үзебезнең девелоперлар исә яңа төзелгән фатирларны сата алмый интегәләр. Апрель аенда фатирга сорау 98–99 процентка кимегән шәһәрләр байтак.

ҖИР ЭШЛӘРГӘ ТИЕШ

Татарстанда заманча цифрлы технологияләр ярдәмендә 113 мең гектар мәйданда ташландык җир ачыкланган. Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мөслимдә авыл хезмәтчәннәренең эшмәкәрлек активлыгын үстерү мәсьәләләре буенча үткәрелгән зона киңәшмәсендә шул хакта белдерде.

tatarstan.ru

Авыл фермерлары һәм эшмәкәрләренә дәүләт ярдәме мөмкинлекләре, көн кадагындагы мәсьәләләр буенча фикер алышу республиканың көнчыгыш зонасына керүче 14 район башлыгы, башкарма комитетлар, авыл җирлекләре башлыклары катнашында узды.

Мөслим районына аяк басуга, Фәрит Мөхәммәтшин Премьер-министр урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров, район хакимияте башлыгы Альберт Хуҗин, Дәүләт Советы депутатлары белән предприятиеләр, оешмалар, фермер хуҗалыклары, авыл хуҗалыгы кооперативлары продукциясе күргәзмәсен карады. Күргәзмә район мәдәнияте йорты фойесына урнаштырылган.

Мөслим районының «Визит карточкасы» – көшчылык фермалары. Узган елда районда 30 көшчылык фермасы эшләсә, быел аларның саны 35кә җиткән. Соңгы елларда бу тармакка инвестицияләр күләме 1 миллиард сум чамасы тәшкил иткән. Альберт Хуҗин билгеләп үткәнчә, район фермерлары җитештерүдә яңа технологияләрне киң куллана. Мөслим районы республикада кош-корт ите җитештерү буенча – алтынчы, фермер хуҗалыклары арасында – беренче урында.

Дәүләт Советы Рәисе киңәшмәдәге чыгышында Татарстан Президенты тарафыннан куелган бурыч – авыл хезмәтчәннәренең эшмәкәрлек һәм социаль активлыгын үстерү бурычын искә төшерде. «Бүгенге катлаулы вазгыять шартларында азык-төлек иминлеген тәэмин итү мәсьәләсе аеруча әһәмиятлегә әйләнә, – дип басым ясап әйтте ул. – Беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итү, халыкның мәшгульлеген саклау, төп оешмаларның өзлексез эшләвен тәэмин итү, бизнеска яңа шартларда булышу өстенлекле максатлар булып тора. Беренче этапта логистика системасын үзгәртеп кордык һәм азык-төлек, дарулар, беренче чиратта кирәкле товарлар белән тәэмин итүдәге өзеклекләрне бетердек. Хәзер бәяләрнең нигезсез үсүенә юл куймаска тиешбез».

Парламент башлыгы фикеренчә, республикада кече хуҗалыкларны үстерүгә зур әһәмият бирелә. «Бүген кече хуҗалыклар исәбендә 470 меңнән артыграк шәхси ярдәмче хуҗалык, 4 меңнән күбрәк фермер хуҗалыгы һәм 300дән артык авыл хуҗалыгы куллану кооперативы бар, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Һәр ел саен кече хуҗалыкларны үстерүгә грантлар һәм субсидияләр рәвешендә 2 миллиард сумнан артыграк акча бирелә. 2016 елдан «Татарстанда шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» республика законы гамәлдә булып килә. «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» дәүләт программасы өчен 1,5 миллиард сум каралган. 34 районда 5 мең кв. м торак мәйданы, 84 объект төзү, челтәрләрне, бинолар һәм корылмаларны капиталь төзекләндерү мөмкинлеге бирәчәк бу. Сыерларның баш санын – 1840ка, атларны – 840, кош-кортны – 540 меңгә җиткерүне көтәбез».

Районнарда хуҗалыкларның нәтиҗәле эшләвен арттыру өчен мөмкинлекләр бар. Файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы объектлары һәм хуҗасыз җирләр шул исәпкә керә. Россельхознадзорның республика буенча идарәсе 4,6 миллион гектардан артыграк мәйданда авыл хуҗалыгы җирләренә мониторинг үткәрде, – диде парламент башлыгы. – Заманча цифрлы технологияләр ярдәмендә 113 мең гектар мәйданда ташландык җир ачыкланды. Бу җәһәттән көнчыгыш зонага керүче районнарга да тәкъдим ителәчәк. Әлеге мәсьәләгә игътибарны көчәйтеп, ташландык җирләрне эшкә җигәргә кирәк».

Аермасын саулыктан!

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Татарстанның Республика клиник хастаханәсе мәйданында югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтү корпусы төзеләчәк. Бирәдә трансплантология (органнарны күчереп утырту) бүлеге дә булачак.

– Трансплантология өлкәсе республикада уңышлы үсә. 2017–2018 елларда без бер пациентка бавыр күчереп утырттык. Быелтыр исә – 28, быел 30 авыруга шундый операция ясарга ниятлибез, – диде Марат Садыйков. Яңа үзәк бөтен Идел буе округы өчен трансплантация юнәлешендә бердәм ярдәм күрсәтү урыны булачак дигән килешүләр дә бар. Әле проектның купмегә төшәсе, нинди чыгымнар таләп ителәсе билгеле түгел икән.

Тик менә «Салават күпере» микрорайонында яшәүчеләргә быел бәхет елмаймас шул. Сырхауханә төзелеше бирәдә кабат кичектерәчәкләр. «2022 елда төзелеш эшләрен башларбыз дип уйлаган идек. Тик аны 2023 елга күчерелүе сәбәпләр барлыкка килде», – дип аңлатты Марат Садыйков.

Бер елга – 7,5 млрд сум. Татарстанның төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры Марат Айзатуллин сүзләренчә, быел төрле федераль, республика программалары һәм программадан тыш чаралар буенча Татарстанда сәламәтлек саклау объектларын төзү һәм ремонтлау эшенә шулкадәр акча юнәлдереләчәк. Шунысы да куанычлы: төзелеш программалары үзгәреш кичермәячәк. Ягъни төрле санкцияләр аларның бюджетына кагылмаячак. «Планда каралган барлык корылмалар үз вакытында һәм тиешле сыйфатта башкарылып, файдалануга тапшырылачагына шик юк», – дип ышандырды министр.

Марат Садыйков та үз юнәлеше өчен тыныч. Чикләүләр кыйммәтле медицина җиһазларының бәясенә йогынты ясамаган.

– Кыйммәтле җиһазлар дигәндә компьютер томографы, ангиограф, онкологик диспансерлар өчен җиһазларны күздә тотабыз. Россиягә карата алып барылган санкция сугышы аларның бәяләренә тәэсир итмәде. 2021 елгы бәяләр калды. Аларны кайтарту буенча сораулар туарга мөмкин. Без Россия белән дус илләр – Төркия, Казахстан, Әрмәнстан һәм башка илләр белән бу сорауга ачыклык кертергә тырышабыз, – диде тармак министры.

Яңарыш медицина белгечләрен әзерләүче уку йортларына да кагылачак. Марат Садыйков әйтүенчә, тармак медицина училищелары һәм көллиятләрен, тулай торакларны заманчалаштыру буенча программа әзерли. «Берничә дистә ел дәвамында үзгәреш булмаган иде. Чыгарылыш укучыларына хәзер таләпләр дә башка бит», – дип аңлатты Марат Садыйков.

Сүз уңаеннан, белгечләрне кайтару ысуллары да шул ук кала: максатчан укыту, фатир белән тәэмин итү, грант, акчалата кызыклау.

«Сәламәтлек саклау» илкүләм проекты кысасында быел ил буенча беренче фельдшер-акушерлык пункты Татарстанда – Лениногорск районының Тимәш авылында ачылачак. Бина иске медпункт урынына төзелгән. Төзеклендерү өчен тотылган сумма күләме – 8190,36 мең сум. Яңа бина барлык кирәк-яраклар белән тәэмин ителгән. Фельдшер-акушерлык пунктлы 793 кешегә медицина ярдәменнән файдаланырга мөмкинлек бирәчәк. 2022 елда шушы ук программа буенча республикада 29 фельдшер-акушерлык пункты ачылачак.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Олы юл башы

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Саубуллашу тантаналары, чыгарылыш кичләре тыныч кына үтсен, укучылар хәмергә урелеп, бәйрәм ямен җибәрмәсен иде инде. Башкортстанда «Соңгы кыңгырау» бәйрәме көннәрендә исерткеч эчемлекләр сатуны тыярга җыенулары турында ишеткәч, газетабызның «ВКонтакте» челтәрендә: «Чыгарылыш кичәсендә исерткеч эчемлекләр сатуны тыярга кирәкме?» дигән сораштыру уздырдык. Тавыш бирүчеләрнең 54,38 проценты – «тыярга кирәк», 39,38 проценты – «эчәсе кеше барыбер эчә» 3,75 проценты – «кирәкми», 2,5 проценты «миңа барыбер» дип җавап биргән. «Мәгънәсез закон. Кеше аны алдан алып куя инде». «Бөтенләй тыйсалар, яхшы булыр иде» дигән җаваплар калдыручылар да бар. Бу уңайдан Татарстан Әтиләр берлеге рәисе Гадел Заһретдиновның фикерен дә белештек.

– Чыгарылыш кичәләре, «Соңгы кыңгырау» – балалар һәм әти-әниләр тормышында истәлекле вакыйга. Әлеге чараларның якты, күңелле бер бәйрәм булып истә калуын телим. Бу көнне хәмер сатуны тыяргамы, юкмы? Монда җитәкчелектән бигрәк, һәркемнең үз фикере булырга тиеш. Бу көнне исерткеч эчемлекләр куллану әлеге вакыйганың әһәмиятен күтәрергә мөмкин дип уйламыйм. Тик, икенче яктан, район, шәһәр җитәкчелеге балалар иминлеге өчен кирәк дип шундый чикләүләрне кертергә кирәк дип санаса, мин каршы түгел. Теләсә кайсы очракта һәр әти-әни шуны истә тотарга тиеш. Беренче чиратта, баласының иминлеге – аның кулында, – диде Гадел Заһретдинов.

Татарстан мәгариф һәм фән министры
Илсур ҺАДИУЛЛИН
КОТЛАВЫ

– Кадерле укучылар! Олы дөньяга беренче адым килачәккә дөрес юнәлеше сайлаудан башлана. Йөрәгегезне тыңлагыз, үз-үзегезгә ышаныгыз, кыю булыгыз, кыенлыклардан курыкмагыз, шул вакытта максатка илтә торган юлларның ачылганын күрерсез. Сез яшь, күңелегездә планнарыгыз да, аларны гамәлгә ашырырга җитәрлек мөмкинлекләр, көч һәм энергиягез дә күп. Чын күңелдән сезнең хыялларыгызның чынга ашуын телим. Берничә көннән җитди сынаулар – дәүләт имтиханнары башлана, аларны бөтен белемегезне, сәләтегезне, тырышлыгызны куеп, уңышлы үтәрсез, дип ышанам.

Хөрмәтле мөгаллимнәребезгә тирән хөрмәт белән сугарылган рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Сезнең фидакарь хезмәтегез нәтиҗәсендә без республикада белем бирүнең югары дәрәҗәсе һәм сыйфаты белән горурлана алабыз. Килачәктә укучыларыгыз сезне, мәктәбегезне җылы итеп искә алырлар, Татарстаныбызга дан китерерләр һәм республикадан читтә дә аларның мактаулы исемнәрен ишетеп горурланырбыз дип өметләнәм!

Кадерле әти-әниләр, сез уку елы дәвамында балаларыбыз белән гел янәшә булдыгыз, һәрдаим ярдәм иттегез. Килачәктә аларның сезгә терәк-таяныч булуларын телим, бәхетле һәм уңышка ирешүчән булсыннар, өметләрегезне акласыннар!

БЕРӘҮГӘ ҖЫЛЫ, ИКЕНЧЕСЕНӘ САЛКЫН КИРӘК

Яшәеш

«Татарстанның торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендә иҗтимагый контроль буенча төбәк үзәге» башкарма директоры Дмитрий Романов әнә шулай ди. Үзләренә торак-коммуналь хуҗалык өлкәсендәге сораулар белән килучеләрне күздә тота ул.

vk.com

Дөрестән дә, өйдә эссе булса, җылыны сүндерүләрен, урамда салкын торса, кабызуларын сорыйбыз. Баксаң, теләк белән генә эрак китеп булмый. Ярый ла фатирың яки йортың шәхси казан белән җылытылса. Әгәр җылы үзәкләштерелгән система буенча килсә, өстенә калынрак киенергә дә кайнар чәйне күбрәк эчәргә генә кала.

– Без ел дәвамында халыкның зарларын тыңлыйбыз. Бүгеннән июнь ахырына кадәр, 2021–2022 елда җылыту сезоныннан канәгатьме-юкмы икәнен белер өчен, халык арасында сорашты уздырабыз, – ди ул. – Кызганыч, бер сүндергәч, җылыны кире кушу – катлаулы эш. Җылыны кайчан кушарга, кайчан туктатырга икәнен җирле үзидарәләр хәл итә. Инде әйткәнемчә, халыкка ярап булмый. Кемгәдер эссе, кемгәдер салкын кирәк. Соңгы өч ел эчендә безгә килгән мөрәҗәгатьләрнең 30 процентын җылы бирүгә бәйле сораулар, 50 процентын подъездда ремонт эшләренең вакытында булмавы турындагы зарлар, 20 проценты тирә-якны тәртиптә тоту проблемалары, мелекчеләр белән җыелышлар булмау тәшкил итә.

Дмитрий Романов сүзләренчә, алар халыктан йорттагы гомуми исәпләгечләрнең, җылылык китерү торбаларының сыйфаты, температураның нормативларга туры килү-килмәве, һава торышын көйли торган төймәләрнең бармы-юкмы икәнен дә сорашачак.

– Без үзәктә күп кенә кешеләрнең торак-коммуналь хезмәтләргә бәйле сорауларына җавап кына табып калмыйбыз, аларның белемнәрен дә арттырабыз. Махсус укытабыз. Күпләр инде хәзер идарәче оешманың дөрес эшлиме-юкмы икәнен чамалый башлады, – ди Дмитрий Романов. – Быел җылылык проблемасы бик актуаль булды. Шунысын да онытмагыз: йорт почмагындагы фатирларда температура – 20, калганнарда 18 градус җылы булырга тиеш. Әгәр нормадан ким икән, әлбәттә, бу хакта идарәче оешмага әйтүегез кирәк. Безгә килучеләр арасында торак-коммуналь хезмәтләр өчен түли алмаучылар да җитәрлек. Бүген республика халкының 9 млрд сум әҗәте бар. Ни өчен шулкадәр күп бурыч җыела соң? Безгә килучеләр арасында авыр хәлдә калган гаиләләр күп. Эшсез калучылар, күпбалалы гаиләләр дә бар. Шуңа да без мондый кешеләр белән суд приставлары түгел, идарәче оешма вәкилләре эшләргә тиеш дип саныйбыз.

Дмитрий Романов, кешеләр үз хокукын белеп бетерми, дигән фикердә. Баксаң, подъездлардагы ремонт 3–5 ел эчендә үткәрелергә тиеш икән. Әмма аны кайбер идарәче оешмалар капиталь төзекләндерү белән бергә үткәрә. Кайчан 15 елга бер эшкә тотынучылар да бар. Дмитрий Романов, болай эшләү дөрес түгел, ди.

– Халык идарәче оешмага күрсәткән хезмәте өчен акчасын түли икән, сыйфат беренче урында булырга тиеш. Без уздырган сорашты подъездлар, йорт эчендәге почта әрҗәләре, домофоннар торышының чынбарлыгын ачып бирәчәк. Безнең хезмәткәрләр бу урынга килеп, аларны үз күзләре белән күрергә җыеналар. Аннары инде йорттагы проблемаларны дәүләт органнарына җиткерәчәкләр. Сораштыруда катнашу өчен безнең үзәкнең сайтына керергә кирәк, – ди ул.

Күп әйбер идарәче оешмадан тора дигән фикердә Дмитрий Романов. Әмма тагын өстәп тә әйтеп куя: «Кайдадыр бер милекчеләр ширкәте белән идарә итә алмаучы җитәкче булса, кемдер берничә оешма белән аңлашып эшли».

– Барыннан бигрәк уртак тел табу кирәк. «Безнең ишегалды» программасы буенча эш башлагандa да уртак фикергә килә алмаучылар була. Күршеләрне дуслаштыру уебыз да бар әле безнең. 3 июнь көнне «Халыкара күршеләр көне»н билгеләп үтәргә җыенабыз. Мондый чара аларны берләштерер дип уйлыйбыз, – ди ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

АВЫЛ МАЛАЕ

Хәтер

Быел Туфан ага Миңнуллинның бакыйлыкка күчүенә ун ел тулды. Һәм менә инде ун ел буе әдипнең туган авылы Олы Мәрәтхуҗада Туфан ага рухына Коръән укыла, аш үткәрелә.

Без, гадәттә, Мәрәтхуҗага август баенда, аның туган көнендә җыела идек. Быел мине 21 майга дәштеләр. Бармый каламмы соң? Заманында, әле колхозлар яшәгәндә, Мәрәтхуҗада партоешма секретаре булган, бүген «Таттелеком» элемтә оешмасының Кама Тамагындагы бүлекчәсен җитәкләгән Миңнур Нәбиуллин чакырды мине. Без аның белән ел әйләнәсе хәбәрләшеп яшибез. Туфан ага нигезендәге хәлләрне Миңнур аша белеп торам. Чөнки әдип нигезенә ул күз-колак булып тора. Әгәр Туфан аганың туган авылы булмаса, Олы Мәрәтхуҗаны бүген бар дип тә белмәсләр иде, бәлки.

Туфан ага кайчандыр: «Мине чит илләрдә хөрмәтләсәләр, әллә ни исем китмәс кебек, ә менә туган ягымда хөрмәт итмәсәләр – мин беркем түгел», – дигәнрәк сүзләр әйткән иде. Ул үзе дә туган авылы өчен яшәде, депутат эшеннән, җәмәгать эшләреннән аерылып торырга аз гына вакыт тапса, Мәрәтхуҗа ягына каера иде. Ә авыл халкы аның турында: «Безнең Туфаныбыз», – дип кенә тора. Мәрәтхуҗа кешеләре «Таттелеком» оешмасының элекке җитәкчесе Лотфулла Шәфигуллинга, аның белән эшләгән кешеләргә дә бик рәхмәтле. Мәрхүм шагыйрь Рөстәм Зәкуанны да телгә алдылар. Туфан ага нигезенең ташландык хәлгә калуына йөрәге әрнеп, ихлас күңелдән елап утырган, Туфан бүлмәсен торгызу эшләре башлангач, Мәрәтхуҗа юлларын таптап, такырлатып бетергән Рөстәм рухына догада булуларын да әйттеләр.

Авыл халкы Дәүсовет Рәисе урынбасары Марат Әхмәтовка да бик рәхмәтле. «Ул килмәгән булса, авыл башыннан Туфан йортына хәтле асфальт җәймәсләр иде. Аңа бездән сәлам әйтегез!» – дип калдылар. «Ярар», – дидем инде үзе, әмма телдән җиткерә алмасам, газетада укып белер дип уйлыйм. Марат Готыф улы – татар матбугаты белән даими танышып баручы сирәк җитәкчеләрнең берсе. Мәрәтхуҗа кешеләре депутатлар Разил Вәлиев, Азат Хамаевны да рәхмәт белән телгә алдылар. Миңнур Нәбиуллин да: «Туфан ага музееен әдипнең Кама Тамагындагы музее филиалы итәргә алар булышты», – ди. Музей өчен штат та булдырганнар. Туфан аганың күршесе Гөлнара Хәлиуллина әдип нигезен үз өе кебек карап тота. Аңа ире Илфат булыша. Миңнур Нәбиуллинның хатыны Рәсимә музей фонды өчен җаваплы икән, бу эшкә кемдер кушып түгел, үзе теләп алынган. Кыскасы, хәтер сагында – авылның үз кешеләре. Коръән ашын да үзләре үткәрделәр.

Дөрес, мондый уйны халык күңеленә Миңнур салып куйган, Җиңү көненә багышланган җыелышта: «Җәмәгать, Туфан ага рухына багышлап, Коръән ашы үткәрик әле», – дигән. Мәрәтхуҗалылар аның сүзләрен шатланып кабул иткән.

Ул көнне матур киемнәрен киеп, башларына ап-ак шәлләр бәйләгән апа-сеңелләрнең, түбәтәйле ир-егетләрнең урам буйлап Туфанга барулары күңелне йомшартты. Үзендә туган шәхесләрне шулай олылаучы, вафат булганнары рухына әледән-әле Коръән ашлары үткәрүче авыллар тагын бар микән, дип уйлап куйдым. Клуб мөдире Айрат Кадыйров: «Ашка ярты авыл килде», – дип елмайды. Аның елмаюын аңлыйм, бүген Мәрәтхуҗада нибары 41 кеше яши, ә килүчеләр егермедән артык иде.

Ирексездән Гариф Ахунов искә төште. Шул ук Лотфулла һәм аның кешеләре Гариф абыйның туган авылы Өчиледә «Ахун чишмәсе» эшләгәннәр иде. Шуны ачу тантанасында берәү: «Гариф абый туган көнгә мин бөтен авыл кешеләрен чакырам, дип әйтергә ярата иде», – диде. Бактың исә ул заманнарда Өчиледә нибары өч йорт булган, йортлар саны беркайчан да шуннан артмаган. Хәзер Өчиледә бер йорт та юк, нигезләрен дә үлән каплап бетергән. Шуны Мәрәтхуҗа кешеләренә дә сөйләп алдым әле. Моңсу гына елмаештылар. Ә Миңнур белән Айрат беравыздан: «Мәрәтхуҗа бетмәячәк, аны Туфан абый саклый», – диделәр. Бу авылда ике яклы мәхәббәт яши. Халык әдипнең Мәрәтхуҗа өчен ниләр эшләгәнен онытмый, бармак бөгә-бөгә санап чыга ала. Бер йортын мәктәпкә дә биргән ул, юлларны рәткә китерткән, авылда калырга теләгәннәргә йортлар салырга, клуб төзергә, авылга газ-су кертергә дә булышкан. Яшерен-батырын түгел, арабызда авылдан бер киткәч, кайтып аяк басмаучылар да бар бит әле.

Ә Мәрәтхуҗа халкы бүген Туфан агага әҗерен кайтара. Ике көннең берендә дигәндәй, аның исемен телгә алмаган кеше юктыр. Аның пьесалары буенча куелган спектакльләрне караганда: «Бу хәлләр безнең авылда булды», – дип сөйләнәләр. Миңа да: «Минһаҗ маҗаралары» герое – безнең авылның Миннеҗаны ул. Яман ялганчы, арттырып сөйләүче кеше иде», – диделәр. Булыр, булыр, әмма ялганлый белеп ялганлаучыны Туфан ага хөрмәт итә иде. Ул андыйларда, бәлки, иҗат кешесен күргәндер: «Ну, егетләр, шәп итеп, оста итеп ялганлыйсыз да инде, чынлап торып ышанасы килә бит», – дип сокланып әйткәнен үземнең дә ишеткән бар.

Бөтен барлыгы белән авыл малае иде Туфан ага. Барлык бөекләргә хас булганча гади иде ул, кече күңелле, кешелекле иде. Халык аны шуның өчен дә ярата, хөрмәт итә.

Китәр алдыннан берәүнең Туфан абыйны төшендә күрүен әйттеләр һәм моны үзләренчә: «Коръән ашы уздырасы булганга кергән инде ул», – дип юрап та куйдылар. «Ятсам – төшемдә, торсам – исемдә» дигәннәре шушы буладыр инде ул.

Таралышканда Коръән укыган мулла Илдус хәзрәт: «Инде бернинди югалтуларсыз тагын җыелырга язсын», – дигән иде. Мин моны Олы Мәрәтхуҗаның, Туфан ага турында хәтернең озын гомерле буласына юрадым.

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

922 2022

1100 еллык тарих

Тарих фәннәре докторы, профессор Фаяз ХУҖИН ярдәме белән 1100 ел элек Идел Болгарстанында ислам дине кабул ителү уңаеннан тарихи язмалар циклын дәвам итәбез. Болгар шәһәрләрендә озак еллар казу эшләрен алып барган, ислам дине тарихын өйрәнүгә зур көч куйган галимгә шушы уңайдан сорауларыгызны да җиткерә аласыз.

Идел Болгарстаны шәһәрләре

Шәһәр һәм шәһәр мәдәнияте – мөселман цивилизациясенең мөһим өлеше. Бу культура Идел Болгарына да үтеп керә. Моңа Биләр, Сувар, Алабуга, Муром (Мөрән?) һәм эреле-ваклы башка шәһәрләрдә ачылган мәчет һәм җәмәгать мунчалары калдыклары дәлил булып тора.

Болгар Россиянең Идел-Урал төбәгендәге иң борынгы шәһәрләрдән санала. Ибн Фадлан үзенең язмаларында бу шәһәрне бер тапкыр да искә алмаган. Күрәсең, дөньядагы иң зур шәһәрләрнең берсе – Багдадтан чыккан кешегә яңа гына барлыкка килә башлаган Болгар нык тәэсир итмәгәндер. Әмма соңгы елларда үткәрелгән археологик казу эшләре Болгарның инде X гасырда ук чын шәһәр булуын раслый. Яңа материаллар халыкның нигездә һөнәрчелек һәм сәүдә белән шөгыльләнүе турында сөйли. Казылмалардан кара металлургия һәм тимерчелек эше, чүлмәк һәм күн җитештерү белән бәйле табылдыклар килеп чыкты. X гасыр башында тупланган культура катламында сакланып калган көмеш тәңкәләр һәм шул тәңкәләрне сукканда кулланыла торган инструментлар Болгарның ил сәүдәсендә тоткан әһәмиятен тагын бер кат күрсәтә.

Биләр – Идел Болгарстанының иң зур шәһәре. Аның рус елъязмаларында теркәлеп калган атамасы – Олуг шәһәр (Великий город). Аңа нисбәтле язмалар елъязмаларда сакланып калган.

1183 елда Владимир кенәзе Всеволод Зур Оя Болгар иленә яу оештыра. Бу гаскәр Идел буйлап төшеп, Кама ягына керә, ике көн буена Тухчин шәһәрен камап торганнан соң, өченче көнне Олуг шәһәргә юнәлә. Всеволод үзенең союзниклары белән Олуг шәһәрне ун көн буе камалышта тота, әмма шәһәр халкы бирешми. Шуннан соң ул, болгарлар белән солых төзеп, кире кайтып китәргә мәҗбүр була.

1220 елда урыс елъязмачылары Святослав исемле кенәзнең Ошель (Ашлы) шәһәренә ясаган хәрби походы турында язалар. Әлеге яу вакытында Ашлы бик нык җимерелә, яндырыла. Бу хәбәр Олуг шәһәргә соңлап кына килеп җитә һәм шуңа күрә болгар патшасы тарафыннан җибәрелгән ярдәм дә нәтиҗәле булмый.

Биләр-Олуг шәһәр турында урыс елъязмаларында тагын ике хәбәр бар һәм аларның икесе дә монгол-татар яуларына нисбәтле.

Биләрдә, 1973 елгы аэрофото материалларына таянып, 30дан артык кирпеч бина урыны ачыкланган. Аларның әле өчесе генә тикшерелгән. Казу эшләре дәвам итә.

Сувар Болгар иленең иң атаклы тарихи һәйкәлләре исемлегендә урын алган, шуңа күрә аны еш кына шәһри Болгар белән янәшә куеп телгә алалар. Ул хәзерге Спас районының Кузнечиха авылыннан дүрт чакрым ераклыкта урнашкан. Борынгы кала 90 гектар мәйданны биләгән. Баштан ук ул сувар-савир исемле эре кабилә берләшмәсенең – Сувар әмирлегенең үзәге, башкаласы сыйфатында төзелә. Шуңа күрә дә биредә Шәрык илләреннән килгән сәүдәгәрләр, сәяхәтчеләр еш булганнар. Суварны үзләренең язмаларында телгә алалар. Мәсәлән, гарәп географы әл-Балхи хезмәтендә, Сувар – зур шәһәр, аның үзәк мәйданында Җәмигъ мәчет урнашкан, халык саны 10 меңгә җитә, дигән хәбәр бар.

Суварда иң беренче һәм иң күләмле казу эшләрен Мәскәү археологы атаклы болгарчы-галим Алексей Смирнов 1933–1937 елларда үткәрә. Ул тикшергән корылмаларның иң кызыклысы – X гасыр ахырында ук салынган кирпеч бина калдыклары. Гомуми мәйданы – 96 квадрат метр. Үзәкләштерелгән ягу системасы – идән астыннан үтә торган төтен юллары сакланып калган. Галим бинаның борынгы «кыяфәт»ен күз алдына китереп, аның якынча реконструкциясен дә ясап куя: артык зур булмаган тәрәзәләр, як-яктан ярымколонналар куелган арка тибындагы киң һәм биек ишек. Ишегалды кирпеч белән түшәлгән. Галим әлеге бинада Сувар әмире торгандыр дип фаразлаган.

Ошель (Ашлы) – Иделнең уң як ярында урнашкан Болгар шәһәре. Хәзерге вакытта аның археологик калдыклары Татарстанның Тәтеш районы Богдашкино авылыннан төньякта урнашкан 77 га мәйданлы шәһәрлек урынында дип фаразлана. Ошель рус елъязмаларында Владимир-Суздаль кенәзенең Идел болгарларына 1220 елда чапкан яуларына бәйле рәвештә дип беренче һәм соңгы тапкыр телгә алына. Бу яу вакытында Ашлыны бик каты талыйлар, яндыралар һәи җимерәләр. Шәһәр яңадан торгызылмый. Шәһәр археологик яктан өйрәнелмәгән диярлек. Ул үзенең тикшерүчеләрен көтә.

Муром шәһәрлеге – Биләрдән соң болгар тарихының монголларга кадәрге чорына караган иң зур археология һәйкәле. Ул Самара өлкәсендә, Болгар дәүләтенең көньяк чигендә урнашкан. Шәһәрнең мәйданы – 400 гектардан артыграк. Тарихи исеме билгеле түгел. Мөрән булмадымы икән дип уйлаучылар бар, әмма тәгаенләп әйтү кыен. Муром шәһәрлеге – бай шәһәр, болгарларның хәзерге Самара төбәгендә яшәгән зур гына бер төркеме өчен административ үзәк булып хезмәт иткән. Монгол-татарлар явы вакытында яндырыла һәм яңадан торгызылмый.

Идел Болгарының шактый зур шәһәрләре исемлегенә шулай ук X–XI гасыр чигендә, дәүләтнең төньяк һәм төньяк-көнчыгыш чикләрендәге форпостлар, **Кашан, Кирмән, Алабуга** һәм тарихи исемнәре язма чыганакларда телгә алынмаган башка шәһәрләр керә. Болгар дәүләте чикләреннән тыштa, Иделнең түбән агымы төбәгендә, кыпчаклар яши торган өлкәдә, урта гасыр сәяхәтчеләре **Саксин** дигән шәһәрне еш телгә алалар. Әбү Хәмид әл-Гарнати, мәсәлән, шул Саксинда күп төрле халыклар, алар арасында сәүдәгәрләр, дәрәҗәле мөселман укымышлылары яшәүләре турында сөйли.

Идел болгарларының хәзерге Пермь өлкәсендә **Афкула** исемле шәһәре билгеле. Аның хәрабәләре (Рождественск шәһәрлеге) соңгы елларда археологлар тарафыннан яхшы өйрәнелде. Шәһәр янында мөселман зираты урнашкан. Афкула борынгы коми-пермяклар җирендә болгарларның сәүдә урыны ролен үтәгән. Биредә, әлбәттә, һөнәрчеләр дә яшәгән. Шәһәрнең бер почмагында болгарларның чүлмәк яндыру мичләре казып тикшерелгән.

«Рус тарихының атасы» Василий Татищев: «Болгарлар – шәһәр төзелешендә дан яулаган халык», – дип яза. Һәм ул, һичшиксез, хаклы була.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсешенә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры **Кәримов** Альберт Әнвәр улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

* * *

Законлылыкны ныгытуга, гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклауга зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Арбитраж суды суд составы рәисе **Гарәпшина** Наилә Дамир кызы; Татарстан Республикасы Арбитраж суды суд составы рәисе **Красавина** Венера Шамил кызы; күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм республиканың сәнәгать комплексын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының техник үсеш буенча урынбасары – баш инженеры **Драгунских** Игорь Викторович; республикада гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе хокук, оештыру һәм кадрлар белән эшләү бүлеге башлыгы **Захаренко** Ольга Николаевна; финанс-икътисади эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен Татарстан Республикасы Арбитраж судының финанс-икътисад бүлеге башлыгы урынбасары **Моисеева** Ольга Леонидовна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш бухгалтеры **Гаршина** Ольга Георгиевна, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының финанс-икътисад бүлеге башлыгы **Мөхәммәтшина** Рауза Әдһәм кызына, «ТаграС-Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директорының икътисад һәм финанслар буенча урынбасары **Сергеев** Сергей Владимировичка, Татарстан Республикасы Арбитраж судының финанс-икътисад бүлеге башлыгы **Скрипова** Наталья Геннадьевнага, «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең икътисад һәм финанслар буенча проректоры – баш бухгалтеры **Шәмиева** Альбина Илһам кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Вишневская** Ольга Владиславовнага, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе киңәшчесе **Гыйздәтуллин** Аяз Наил улына, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе адвокатура, нотариат өлкәсендә контроль һәм күзәтчелек, гражданлык хәле актларын дәүләт теркәве бүлеге башлыгы урынбасары **Землянская** Аэлита Морат кызына, Татарстан Республикасы Арбитраж суды судьясы **Кириллов** Алексей Евгеньевичка, Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы киңәшчесе **Нотфуллина** Зәринә Наил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ЕГЕРМЕ ИКЕНЕҢ САЛКЫН ЯЗЫ,

ЯКИ САГЫНДЫРА ИКӘН КОЯШ ТА...

Кышка фаразлары туры килмәсә дә, синоптикларның да, сынамышлар белән шөгыльләнүчеләрнең дә язга юраганы юш килде. Яз салкын һәм яңгырлы булачак дигәннәр иде.

Бу сүзләргә, билгеле, беребез дә ышанмады: өч көнлек һава торышын дөрес әйтә белмәгән башлары белән, диештек. Тик менә инде язның соңгы ае, соңгы көннәре үтеп бара, аяз, җылы, кояшлы көннәр иртә яздан бүгенгәчә бармак белән генә санарлык булды.

Христиан динендәгеләрнең Пасха бәйрәменә һава торышы юньле булмады, кырык көн салкын булачак дигәннәр иде. Анысы да кырыгынчы көненә хәтле төгәл килә бугай. Һава торышыннан зарлану дип кабул ителә күрмәсен, болар – аптыраудан, көчсезлегебезне танудан язылган фикерләр генә. Баштарак, әллә нинди көннәр булыр әле, дигән иң сабырлар да соңгы көннәрдә уйлана башлады. Эшкәртелмәгән бакчасына карап: «Быел бәрәңге утыртып булырмы икән?» – ди алар хәзер. Өлгеррәкләр дә, бакчага чыкса, чын-чыннан аптырап керә. Утырткан, чәчкән әйберләр түгел, чүп үлән дә үсми бит, диләр. Дөрес, арада әле сирәк булса да оптимистлар бар. «Кеше янында әйтергә генә кыенсынам, яратам шушындый һава торышын», – ди бер танышым.

«Үткән ел бу көннәрдә 30–33 градус эсселек булган», – ди берничә көн элек кенә, һава торышын язып баручы икенче бер танышым.

– Әллә ул эсселәрдә рәхәт булдымы, зарланмадык дип беләсеңме? – дим. – «Кыш көне салкын дип тиккә зарланганбыз икән, ул чакта әле киенеп-төренеп йөрергә дә була», – дип язганмын үткән ел җәйге эсселек-корылыктан гаҗизләнгәндә...

Хәер, бу сүзләрне дә аңлап була кебек, 2010 елдан алып, алты ел буе һәм быылтыр җәйләребез күккә карап, болыт көтеп үтте. Кечкенә генә болыт кисәге күрсәк тә, өметләндек, теләдек, ялвардык. Баш өстендә көйдергән, бар нәрсәне рәхимсез куырган кояшны, 35–40 градуслы җәйләрне һич кенә дә сагынмабыз кебек иде. Тик яңгыр да тамчысына сөенерлек чакта гына кадерле, ахрысы. Ул чакта да без корылыктан көйгәндә, кай җирләрне су басты, тоташ яңгыр койды. Быел исә бездә яңгыр, шул ук вакытта сусызлыктан интеккән, корылык аркасында янгыннардан җәфа күргән урыннар бар. Тигезләүче без түгел шул... Безгә исә сабыр гына күнәргә, өлешебезгә туры килгән шартларга яраклашырга, югалып калмаска, нәрсәдер эшләргә, тырышырга гына кала. Табигать безгә кемнең өстен, кемнең җиңүче икәнен аңлата килә шул.

Һәр нәрсәдән тәм-ямь таба белгәннәр рәхәтләнде: соңгы вакытта социаль челтәрләрне кызыклы видеолар, шигырьләр басты. Кемнәрдер «Яңа ел ялларын майга күчерсәң, шулай була ул», «Быел җәй әйбәт килде, барыбер кыштан җылырак», «Җәйләргә дә кереп киттек өсләргә киеп толып» ише иҗат җимешләре белән көлсә-шаяртса, кемнәрдер көчле яңгырлар аркасында Татарстанда су баскан басулар-бакчаларны, кар яуган Башкортстан авылларын куеп уфтанды. «Бездә әле аның кадәр үк түгел икән», – диеп шөкер итүчеләр дә табылды. Ни дисәң дә, табигатьнең үзе кебек үк бай фантазияле, шул ук вакытта каршылыклы да шул без.

Хәер, авыл кешесенә, игенчегә, мөгаен, бер генә язны, бер генә җәйне дә тыныч үткәрергә язмагандыр. Бар яшәеше табигать шартлары, аның белән гармониягә бәйле шул. Һәм, никадәр теләсәк тә, бернине дә үзгәртә алмыйбыз. Печәнсез, бәрәңгесез калмаммы, ашлыклар өлгерерме, җыярга көне булырмы дип, бүгеннән вәсвәсәләнә ул. Әби-бабае да, эшләүчесе дә, җитәкчесе дә шулай кайгыра. Үзе өчен генә түгел, күзенә карап торган терлеге өчен дә җаваплы шул ул... Язлары без теләгәнчә булмады, инде җәйләре хәерле булсын, диярге генә кала.

P.S. Ниһаять, алдагы көннәргә синоптиклар җылы, кояшлы көннәр вәгъдә итә. Сагындыра икән кояш та...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Белдерү

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ГРАНИЦ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Катиным Сергеем Вячеславовичем (аттестат 16-11-169, адрес: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1, тел.: (917) 850-99-44) в отношении земельного участка с кадастровым номером 16:50:221249:14, расположенного по адресу: РТ, г. Казань, ул. 4-я Муромская, дом 17, выполняются кадастровые работы по уточнению местоположения границ и площади данного земельного участка.

Заказчик: Фахрутдинов Тахир Маулитович, адрес: Респ. Татарстан, Кукморский район, с. Яныль, ул. Новая, д. 2, тел.: +79520402940.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границ состоится 30 июня 2022 г. в 9 часов 00 минут по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1.

Ознакомиться с проектом межевого плана и предъявить обоснованные возражения относительно местоположения границ земельного участка можно по адресу: 420138, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Дубравная, д. 51Г, офис 1 в течение 30 (тридцати) дней со дня выхода данного извещения в печать.

Смежные земельные участки, с правообладателями которых требуется согласовать местоположение границ: 16:50:221249:14, 16:50:221249:1, 16:50:221249:11, 16:50:221249:12, 16:50:221249:13, расположены в Республике Татарстан по адресам: г. Казань, ул. 5-я Муромская, д. 18, д. 20, ул. 4-я Муромская, д. 19, д. 15, в границах кадастрового квартала 16:50:22124.

При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий земельный участок.

ИЗВЕЩЕНИЕ О НЕОБХОДИМОСТИ СОГЛАСОВАНИЯ ПРОЕКТА МЕЖЕВАНИЯ ЗЕМЕЛЬНОГО УЧАСТКА

Кадастровым инженером Воронским Михаилом Александровичем (квалификационный аттестат кадастрового инженера № 16-15-821; номер регистрации в государственном реестре лиц, осуществляющих кадастровую деятельность: 35066; СНИЛС 120-706-752-23; 420097, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Карла Маркса, 65, офис 1, e-mail z_pravo@mail.ru, контактный телефон: 8 (843) 258 83 23) подготовлен проект межевания земельного участка с кадастровым номером16:50:010803:109, расположенного по адресу: Республика Татарстан, г. Казань, ул. Н. Ершова, за АЗС, гараж № 76. Заказчиком работ является Тенишев М.Х., +7 917 292 29 92.

Собрание заинтересованных лиц по поводу согласования местоположения границы состоится по адресу: г. Казань, ул. Карла Маркса, 65, офис 1 20 июня 2022 года в 10 часов 00 минут. С проектом межевого плана земельного участка можно ознакомиться по адресу: г. Казань, ул. Карла Маркса, 65, офис 1. Возражения по проекту межевого плана и требования о проведении согласования местоположения границ земельного участка принимаются ежедневно с 9 до 17 часов 00 минут в течение месяца со дня опубликования по адресу: г. Казань, ул. Карла Маркса, 65, офис 1. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок.

Язучы фикере

Марат КӘБИРОВ

Бакча эшләре

Чулпан Гарифуллина

Авылга мин язып кына ятармын дип кайткан идем. Табигатькә, кешеләргә якын җир. Тынычлык. Үз уйларың белән булырга беркем комачауламый. Яз шунда рәхәтләнеп. Бернинди төзелеш, бакча, яшелчә-җимеш кирәкми. Һәркем үз эше белән булырга тиеш. Төзүче – төзергә, бакчачы – үстерергә, язучы язарга тиеш.

Югыйсә әнә узган ел гомер нәрсәдер төзәтеп, бакча утап узды. Быел берәрсе: «Былтыр нәрсә эшләдең?» – дип сораса, менә дип күрсәтерлек эш юк. Бакча утадым! Түтәлләр җәй буе ялт итеп торды. Үзем дә карап соклана идем. Узгынчылар да мактап уза иде. Тик бернәрсә дә юньләп үсмәде. Елы туры килмәде. Бәрәңге унды. Базда черетеп, быел чыгарып түктек. Быел алай итмим дип ант эчтем. Сатып алам барысын да. Күп итеп язсаң, күп итеп акча түлиләр. Ул акчага яшелчәсен дә, җиләк-җимешен дә – барысын да алып була. Шулай дөрес.

Дөресен дөрес тә, ә җирне нишләтергә? Ну, аз гына бәрәңге утыртырмын инде, аз гына яшелчә, аз гына җиләк. Тик күп түгел. Язудан бушаган вакытта бераз ял итеп, селкенеп керерлек кенә. Көнозын компьютерга текәлеп утырып булмый, чүт кенә хәрәкәт тә кирәк ич. Юкка гимнастика ясап көч сарыф иткәнче, бакчада селкенәсең. Гимнастика да ясала, яшелчә-җиләк тә үсә.

Быелгы ел авыр булырга мөмкин, диләр. Мин мәгълүматны төрле чыганаклардан алам инде. Барысы да алдый, әлбәттә. Тик һәркайсы үзенчә алдый. Менә шул ялганнарны бергә кушып бутыйсың-бутыйсың да, кибәкләре кубып төшкәч, дөреслек килеп чыга. Ә дөреслек бик үргә сикерерлек түгел. Тормышның каршылыклары тиз генә бетәргә охшамый, ул әле тагы да катлауланыбрак китәргә дә мөмкин. Бәяләр арта, акча арзаная, эш хакы күтәрелми. Мин инде туксанынчы елларның кибет киштәләрендәге бушлыкны күргән кеше буларак, андый нәрсәләргә тиз ышанучан. Өстәвенә авылдагы дусларның да күбесе: «Кибеттән ярма җыяр хәл юк инде, бәрәңге исән булсын», – дип кенә тора. Алар әле быел бәрәңгене тагы да күбрәк утыртырга уйлыйлар икән. Кайберләре үлән җирен дә сөрдергән. «Юк-юк, үлән дә, чүгендер дә түгел, бәрәңге кирәк, адәм дә, мал да ашый торган ризык», – диләр.

Ну... Тормышның ачысын-төчесен күргән авыл кешесе белми эшләмидер инде. Мин дә алардан калмаска уйладым. Бәрәңге утырттым. Былтыргыга караганда күбрәк тә килеп чыкты әле. Булсын әйдә. Язудан арган чакларда ике тапкыр күбрәк селкенергә туры килер. Хәрәкәттә бәрәкәт бит инде. Кан йөреше тизәйгәч, баш та яхшырак эшли башлый ул.

Авыл халкы барысын да чамалап тора, ничек яшәргә икәнен белә. Бер бәрәңге белән генә булмый, аның янына суган да кирәк икән. Сатып ала башласаң – оһо-һо! Бәясе алтын бәрабәренә тиң. Кемнең үз бакчасында күп итеп алтын үстерәсе килмәсен инде? Утырттым анысын да. Мин аны кыякта чагында ук күп итеп ашыйм әле. Шулай булгач, көзгә дә калырга, кышны да чыгарга, язга да керергә җитсен дип, анысын да күп итеп утырттым. Суган булгач, сарымсагы да кирәк бит инде. Әле теге зәхмәтле чирне беркем дә юкка чыгармаган. Сарымсак ашаган кешегә бернинди чир дә тими. Анысы да күп булырга тиеш. Хәзер аптекаларга якын килерлек түгел, витриналарына «бәя» дип аталган тешләк эт бәйләп куйганнар. Төчкергән саен аптекага йөгерә башласаң, бөтенләй ыштансыз калуың бар. Аптека дигәннән... кишер дә кирәк инде... Анда бит витамин бар икән. Витамин ул кызыл чөгендердә дә, кәбестәдә дә бар инде. Редиска белән шалканда да, кыяр белән помидорда да... Әнисне дә бик мактыйлар.

Шул рәвешле, искә төшкән бөтен файдалы яшелчә-җимешне утыртып чыктым, карап күз сокланырлык булсын дип, чәчәкләр дә үстерергә уйладым. Бакчада нәрсәдер утыртырлык җир беткәч кенә һушыма килгәндәй булдым. Кара әле, атна-ун көн чамасы вакытымны бакчада уздырганмын икән бит. Алданрак утыртылган түтәлләрдә инде чүп чыгып килә. Бәрәңгене дә тырмалап чыгарга кирәк, чүп үләннәр җепсел генә чакта тырмаласаң әйбәт була ул. Сарымсакларның нилектәндер очлары саргая башлаган. Витамин җитмидер инде, җирне ашларга кирәктер. Җиләк түтәлләрендә кырмыска күренгәли, менә анысын да нәрсәдер эшләтергә кирәк.

И-и, мин бит авылга тынычлыкта язып кына ятарга дип кайткан идем. Компьютерны күптән күргән юк икән. Болайга киткәч, тиз генә күрешеп тә булмас инде. Күрсәгез, сәлам әйтегез, яме.

ӨЧ КЫЗ ӘТИСЕ ИЛДУС ЛОТФУЛЛИН:

«БАЛАЛАРЫМА СҮЗЕМНЕ ВАКЫТЫН САЙЛАП КЫНА ӘЙТӘМ»

Үрнәк

Табиб Илдус ЛОТФУЛЛИН белән коронавирус пандемиясе чорында таныштык. Медицина, шушы чиргә бәйле сорау туса, мөрәҗәгать итә торган беренче белгеч иде ул. Илдус Лотфуллинның менә дигән педиатр булуыннан тыш, өч гүзәл кыз әтисе, үрнәк гаилә башлыгы булуын соңрак белдем.

«Өч кыз үстергән ата җәннәткә эләгәчәк икән бит, Илдус Җәүдәтович!» – дип сөйләшеп киттек шулай. Бала тәрбиясе, ата-ананың роленнән башлап, хыялдагы кияүләргә кадәр барып җиттек.

:: Бала, бигрәк тә кыз бала тәрбияләгәндә, ата кешенең роле нинди?

– Бу сораугa ничектер китап сүзе белән, фәнни терминология кулланып җавап кайтарасы килә. Табиб булганга күрә шулайдыр инде. Бала тәрбияләү – төгәл фән, төгәл технология түгел шул. Тормышның үзе кебек үк катлаулы, вакыты белән буталчык процесс ул. «Мин яхшы әтиме, яхшы әниме?» дигән уй һәр ата-ананың башына еш киләдер. Күп еллар балалар белән эшләп, ике нәрсәне аңладым. Беренчедән, балалар алдый белми, алдарга яратмый! Әгәр синең аны чынлап та аңлыйсың, кем икәнен беләсең килсә – ачык китап кебек алар. Син балаң белән чынлап торып кызыксынасың, аңа эмпатия күрсәтәсең икән – ул синнән берни дә яшермәс. Икенчедән, бала үзе дә ялганны, икейөзлелекне бик тиз күреп ала. Бер нәрсә әйтеп, икенчесен эшләсәң, аның синең сүзләрдән күңеле кайта, киңәшләреңне колагына да элми. Шул рәвешле сүзләрең бушка акыл өйрәтү булып кала.

:: Ә сез нинди әти? Балаларыгызга нинди киңәшләр бирәсез? Әнә шул «акыл өйрәтү» булмастайларынмы?

– Кем икәнлекләрен аңларга тырышам. Аларның табигатенә ни салынган? Кем булып яратылганнар бу дөньяга? Нинди юл белән барсалар, бәхетле булып яшәрләр икән? Шуны уйлыйм.

Өч кызым өч төрле. Берсе – командир, буйсындырырга, сүзен өскәрәк чыгарырга ярата. Икенчесе – фәлсәфәче, кечкенәдән үк үз уйларына бирелгән. Өченчесе – бик рациональ тулаш, үз бәясен белә. Аларга хас бу, моны инде үзгәртеп булмый. «Баламны ничек телим, шулай әвәлим», – дип уйлау – зур ялгыш. Бу аралар суынуга китерә. Баланың юлы билгеләнгән инде. Ата-ана баланың табигатен сындырмыйча тәрбия кылырга тиеш. Командир – агрессорга, фәлсәфәче – хыялыйга, рационале саранга әйләнмәсен. Максат шул гына. Хатыным Динә белән без – бу сорауда уртак фикердәш, моның өчен бик рәхмәтле мин аңа.

Киңәшләр дигәннән, сүземне вакытын сайлап кына әйтәм. «Тагын сөйләнә инде әти», – дип уйларлык булмасын. Алар өчен мин – лидер ич! Киңәшемне көтеп торсыннар, бәясен дә белсеннәр.

:: Илдус Җәүдәтович, ә ир бала тәрбияләү хыялы... Булдымы ул?

– Юк. Ходай язса, малайларым туса, малай тәрбияләр идем. Кыз белән малай тәрбиясе аерыла инде ул. Ләкин бу аерма шулкадәрме икән? Йомшак күңелле малайдан – «мужик», кырыс холыклы кыздан «дюймовочка» үстерү – зур ялгыш. Күпчелек гаиләләр шуның белән маташа. Булмый ул! Кеше барыбер үз табигатенә вакыты белән кайта, ә ата-ана йөрәгендә үпкә генә кала.

:: Ә кызларыгыз сезнең нинди сыйфатларны үзләренә сеңдергән?

– Битләре белән миңа охшаган булсалар да, холыклары буенча никтер үземә охшаган дия алмыйм. Башка алар. Буыны да башка ич. Ә миңа охшамасыннар да алар, үзгә булсыннар!

:: Сезгә берничә тапкыр «бабай» буласы, Илдус Җәүдәтович! Нинди кияүләр турында хыялланасыз?

Лотфуллиннар Мәрьям, Асия, Әминә исемле кызлар тәрбияли.

– Кияүләр турында уйлаганым булмады. Ә менә оныкларымны күрәсе килә, әлбәттә! Күз алдына әллә нинди шук-шаян татар малайлары, кызлары килә! Имеш, бергә зур бер эт асрыйбыз, иске генә бер машинага утырып, дөнья гизәбез! Стандарт хыял инде болар. Гаиләле дусларымның яртысы картлыгын әнә шулай күрә. Кияүләр дә булыр әле, көттермәсләр. Фикердәш, милләттәш булсалар, шәп булыр иде!

:: Өч кыз әтисе җәннәткә эләгә, дигән сүз бар. Фәлсәфи яктан килсәк, бу сүзне ник әйткәннәр икән соң? Кыз бала тәрбия кылу шулкадәр авырмы әллә?

– Элекке вакытта өч кызы туган атаны юатыр өчен шулай әйткәннәрдер! Юкмы? Бала тәрбияләү дә – зур эш. Ни дисәң дә, җенескә карамый ул. Бер яктан жылылык, иминлек бирергә тиеш син аларга, икенче яктан тәрбияләп, дисциплинага буйсындырырга! Әле ул иминлек белән дисциплина үзеңә дә җитми бит кайчак. Яхшы әти-әни булу – бик зур хезмәт ул.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

vk.com

БИЛӘРГӘ КАЙТУ

26 июньнән 8 августка кадәр Татарстанның Биләр тарихи-археологик музей тыюлыгында XI Халыкара «Сәләт» яшьләр уку-укыту форумы узачак.

Форум кысасында алты смена оештырылачак. Беренче смена – «Һөнәрләр Биләр форумы» 26 июньдә ачыла. Иҗади смена – «Иҗат Биләр форумы» 3–8 июль көннәрендә узачак. Өченче смена – «Социаль күнекмәләр Биләр форумы» 11–16 июль көннәрендә булыр дип көтелә. «Мәгълүмати технологияләр Биләр форумы» сменасы 28 июльдән 1 августка кадәр узачак. Лидерлык буенча форум 4–8 августта булачак.

Елдагыча, форумнарда Татарстанның барлык район-шәһәрләреннән, Россия төбәкләреннән сәләтле балалар җыелачак. Сүз уңаеннан, «Сәләт»нең төп аланнарына юлламаларның бәясе – 5–22 мең сум. Бәяләр юнәлешкә һәм урынга бәйле. «Сәләт»тә түләүсез ял итү мөмкинлеге дә бар. Мәсәлән, «Сәләт» яшьләр белем бирү форумы тулысынча дәүләт тарафыннан финансланa. Монда килеп эләгү өчен актив булуың кирәк.

Тарихи кыйммәте һәм үзенчәлекләре

– Быел Биләрдәге форумны 11 нче мәртәбә генә уздырсак та, әлеге җирлеккә тәүге тапкыр 1997 елда ук килгән идек. Ул чакта 150–200 бала белән 2–3 көнлек смена уздык. Хәзер инде аланыбыз үсте, зурайды. Юнәлешләр, форматлар артты. Бүген әлеге форум – «Сәләт»нең иң масштаблы чараларының берсе, – дип сөйләде Татарстанның яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов.

Ул «Сәләт»леләрнең яратып әйтә торган «Биләргә кайту» сүзләренә дә аңлатма кертте. «Монда без борынгы бабаларыбыз белән көчле элемтә сизәбез, шуңа да ел саен «кайтабыз». Форумның нәкъ менә Биләрдә уздырылуының тарихи кыйммәте зур. Күп кенә риваятьләр шушы җирлек белән бәйле. Изге чишмә суы гына да ни тора! Миңа калса, балаларны патриотик яктан тәрбияләгәндә тарих битләренә мөрәҗәгать итү – мөһим шарт», – диде ул.

Министр шулай ук форумның үзенчәлекләренә дә тукталды. «Тарихи кыйммәте турында әйтеп киттем. Икенче үзенчәлеге – уку-укыту программасының көчле булуы. Без ел саен балаларга төрледән-төрле өлкәләр белән танышу өчен мөмкинлекләр бирәбез. Биләрдәге очрашулар яңа дуслар, яңа танышулар белән дә кадерле. Һәм, әлбәттә, безнең тагын бер үзенчәлегебез һәм миссиябез – татар теле өчен мохит тудыру. Ләкин шуны әйтергә кирәк: «Сәләт» форумнары һәм сменаларында татарча камил сөйләшә белгән, татар милләтеннән булган балалар гына түгел, теләгән һәркем катнаша ала. Безнең ябык мәйданчык ясыйсыбыз килми. Монда килгәч, саф татарча сөйләшү, фикер алышу теләкләре арта аларның».

Билгеле булганча, Татарстанда 2022 ел Цифрлаштыру елы дип игълан ителде. «Сәләт» яшьләр белем бирү форумының төп юнәлеше дә шушы булачак. Балаларны бу өлкә белән якыннанрак таныштырырга тели «Сәләт»леләр.

Куркыныч янамый

Форумдагы куркынычсызлык һәм иминлек мәсьәләсе турында «Сәләт» яшьләре үзәге директоры Айгөл Габдрахманова сөйләде.

– Әти-әниләр балаларын безгә ышанып тапшыра икән, без бу ышанычны акларга тиеш. Шуңа да без, иң беренче чиратта, куркынычсызлыкны тәэмин итү өчен тиешле таләпләрне кайгыртабыз. Эчке эшләр, Гадәттән тыш хәлләр министрлыклары, Роспотребнадзор таләпләренә буйсынабыз, алар белән эшлибез. Балаларның тән сәламәтлеген генә түгел, психологик иминлеге турында да уйлыйбыз. Бу җәһәттән әйдаманнарыбыз ел дәвамында махсус дәресләрдә, мастер-классларда катнаша. Алар шулай ук форум дәвамында әти-әниләр белән элемтәләрне өзми. Ягъни баланың хәлен алар аша белеп булачак. Әти-әниләр борчылмасын, борчылырга сәбәп юк, – диде ул.

Шулай ук Айгөл Габдрахманова «коронавирус»лы чикләүләрнең бераз «йомшаруын» искәртте. Шуңа бәйле рәвештә быел форумда катнашучылар Биләрнең тарихи урыннарына экскурсияләргә бара алачак. Соңгы ике елда моңа рөхсәт булмаган икән.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7061 данә
Гомуми тираж – 16033 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 272

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+